СОВЕТ
НОВОКИШИТСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Дружба, д. 100а, с. Новый Кишит,
Арский муниципальный район, 422034

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ЯҢА КИШЕТ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ
Дуслык урамы, 100а йорт, Яңа Кишет авылы,
Арча муниципаль районы, 422034

Тел. (84366)55-4-42, факс (84366)55-4-42. E-mail: Nvk.Ars@tatar.ru

**«04» октябрь 2016 ел** **№13**

**Яңа Кишет авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

**Гражданнарның үзара салымын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча Арча муниципаль районының Яңа Кишет авыл җирлеге территориясендә җирле референдумны билгеләү турында**

“Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында” 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы, “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 22, 56 статьялары, “Җирле референдум турында” 2004 елның 24 апрелендәге 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 18 статьясы, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының Яңа Кишет авыл җирлеге Уставының 12 статьясы, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының Яңа Кишет авыл җирлеге Советы карар бирде:

1. 2016 елның 20 ноябренә Яңа Кишет авыл җирлеге территориясендә гражданнарга үзара салым кертү мәсьәләсе буенча җирле референдум билгеләргә.
2. Җирле референдумга чыгарыла торган сорауны расларга:

«2017 елда Яңа Кишет авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 200 сум күләмендә (түләү күләме 100 сум тәшкил иткән укуның көндезге формасында укучы студентлардан, 1,2 группа инвалидлардан тыш) үзара салым акчасы җыю һәм аны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрү белән килешәсезме?

- авылларда юлларны төзекләндерү (вак таш) җәю:
  Кышкар, Симетбаш авылларында;
-яктырткыч лампаларны алыштыру: Иске Кишет, Кышкар авыллары;
-скважина өчен насос алу:
Иске Кишет авылы

Аерым мәсьәләләр буенча экономия барлыкка килгән очракта, авыл җирлеге башкарма комитетына референдумда билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итүгә акча җибәрергә рөхсәт итәргә.

| | |
|---|---|
| әйе | юк |

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http:pravo.tatarstan.ru) һәм Яңа Кишет авылы, Дуслык урамы, 100а йорты, Иске Кишет авылы, Г.Сафиуллин урамы, 26а йорты, Кышкар авылы, Яңа урам, 125 йорт, Симетбаш авылы, Үзәк урам, 19а йорты) мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

4. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Яңа Кишет авыл җирлеге башлыгы Т.А.Арсланов